СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.06.2020 г. Заинск № 542

**«Зәй муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондыннан найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе һәм муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләрен билгеләү турында» 2008 елның 15 сентябрендәге 233 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Советы

# КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондыннан найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе һәм муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләрен билгеләү турында» 2008 елның 15 сентябрендәге 233 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2011 елның 18 гыйнварындагы 49 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәреш белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В.Г. Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**